ГОСУДАРСТВЕННЫЙ
КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ
КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**10.07.2026** г. Казань **№ 610/2026**

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан халык саны биш йөз мең һәм аннан да күбрәк булган җирлекләрдә, шәһәр округларында урнашкан җылылык челтәрләреннән тыш, җылылык энергиясен, җылылык ташучыны җылылык челтәрләре буенча тапшырганда технологик югалтулар нормативларын раслау Тәртибен раслау турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җылылык энергиясен, җылылык ташучыны тапшырганда технологик югалтулар нормативларын билгеләү тәртибен раслау турында» Рәсәй Федерациясе Энергетика министрлыгының 2008 елның 30 декабрендәге 325 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15.06.2010 № 468 карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында Нигезләмә нигезендә, БОЕРЫК БИРӘМ

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан халык саны биш йөз мең һәм аннан да күбрәк булган җирлекләрдә, шәһәр округларында урнашкан җылылык челтәрләреннән тыш, җылылык энергиясен, җылылык йөртүчене җылылык челтәрләре буенча тапшырганда технологик югалтулар нормативларын раслау Тәртибен әлеге боерыкка кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Рәис Р.В. Гайнетдинов

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты боерыгы белән расланган от 10.07.2026 № 610/2026

**Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан халык саны биш йөз мең һәм аннан да күбрәк булган җирлекләрдә, шәһәр округларында урнашкан җылылык челтәрләреннән тыш, җылылык энергиясен, җылылык ташучыны җылылык челтәрләре буенча тапшырганда технологик югалтулар нормативларын раслау Тәртибе**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Тарифлар буенча Дәүләт комитеты (алга таба – Дәүләт комитеты) тарафыннан җылылык энергиясен, җылылык ташучыны җылылык челтәрләре буенча тапшырганда технологик югалтулар нормативларын раслау тәртибен билгели, моңа халык саны биш йөз мең һәм аннан да күбрәк булган җирлекләрдә, шәһәр округларында урнашкан җылылык челтәрләре керми (алга таба – нормативлар).

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр булып бәяләрне (тарифларны) дәүләт җайга салуы гамәлгә ашырыла торган җылылык энергиясен тапшыру һәм бүлү буенча хезмәтләр күрсәтүче юридик затлар яисә шәхси эшмәкәрләр тора, халык саны биш йөз мең һәм аннан да күбрәк булган җирлекләрдә, шәһәр округларында урнашкан җылылык челтәрләренә милек хокукында яисә башка законлы нигездә ия булган юридик затлардан һәм шәхси эшмәкәрләрдән тыш (алга таба – мөрәҗәгать итүче, җайга салына торган оешма).

Мөрәҗәгать итүчеләрнең мәнфәгатьләрен мөрәҗәгать итүче тарафыннан билгеләнгән тәртиптә вәкаләт бирелгән затлар тәкъдим итәргә мөмкин.

## 2. Нормативларны раслау тәртибе һәм үзенчәлекләре

2.1. Нормативларны раслау турындагы мәсьәләне карау өчен нигез булып җылылык энергиясен, җылылык йөртүчене җылылык челтәрләре буенча тапшырганда технологик югалтулар нормативларын раслау турындагы гариза (алга таба – гариза) тора.

2.2. Гаризага әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасы нигезендә нормативларны раслау өчен кирәкле документлар кушып бирелә. Документларга җайга салына торган оешма җитәкчесе имза сала һәм мөһер белән таныклана (булган очракта) (кәгазьдә бирелгәндә) яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имза салына (электрон рәвештә җибәрелгәндә).

Гариза әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасында каралган форма буенча төзелә.

2.3. Нормативларны раслау өчен кирәкле гариза һәм документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан җайга салуның чираттагы чоры башланганчыга кадәрге елның 1 маена кадәр (2026 елдан тыш) тапшырыла.

2.3.1. Тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу элек башкарылмаган оешма Дәүләт комитетына агымдагы елның 1 августыннан да соңга калмыйча (2026 елдан тыш) нормативларны раслау өчен гариза һәм кирәкле документларны тапшыра.

2.4. Мөрәҗәгать итүче документлар тулы күләмдә тапшырмаган яки алар әлеге тәртип таләпләренә туры килмәгән очракта, Дәүләт комитеты мөрәҗәгать итүчегә 1 сентябрьгә кадәр искәрмәләрне бетерү һәм искәрмәләрне исәпкә алып җитмәгән һәм (яисә) эшләп бетерелгән документларны тапшыру кирәклеге турында гарызнамә җибәрә.

2.5. Җайга салынучы оешма тарафыннан 2.4 пунктта күрсәтелгән документларны тапшыру срогы. әлеге тәртипне җайга салынучы оешма дәүләт комитетыннан сорау алган көннән алып 10 эш көне тәшкил итә.

2.6. Нормативларны раслау өчен кирәкле гариза һәм документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән, тапшыру турында хәбәр белән почта аша җибәрү, электрон почта, электрон документ әйләнеше аша тапшырыла.

2.7. Гариза тапшыру көне булып тора:

а) Дәүләт комитетына шәхсән гариза биргән очракта - Дәүләт комитетының электрон документ әйләнеше системасында гаризаны теркәү көне;

б) почта юлламасы аша тапшыру турында хәбәр белән җибәрелгән очракта - почта юлламасы почта юлламасында штемпель белән расланган элемтә оешмасына тапшырылган көн;

в) электрон почта аша, электрон документ әйләнеше аша җибәрелгән очракта – гаризаны Дәүләт комитетының электрон документ әйләнеше системасында теркәү көне.

Гаризаны һәм документларны теркәү вакыты алар Дәүләт комитетына кергәннән бирле бер эш көне тәшкил итә.

Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә кергән гариза ял (бәйрәм) көненнән соң икенче эш көненә теркәлә.

2.8. Нормативларны раслау турындагы гаризаны карау нәтиҗәсе булып тора:

а) тиешле боерык чыгарып, нормативларны раслау турында карар кабул итү;

б) нормативларны раслаудан баш тарту турында карар кабул итү.

2.9. Нормативларны раслау турында боерык яисә нормативларны раслаудан баш тарту турында хәбәрнамә карар кабул ителгән көннән алып өч эш көне эчендә мөрәҗәгать итүчегә нормативларны раслау өчен Дәүләт комитетына мөрәҗәгать итүнең үзе сайлаган ысулы нигезендә бирелә (җибәрелә).:

а) язма рәвештә мөрәҗәгать итүчегә шәхсән яисә тапшыру турында хәбәр белән почта аша җибәреп;

б) электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә яисә электрон документ әйләнеше системасы ярдәмендә.

2.10. Нормативларны раслаудан баш тарту өчен нигезләр булып тора:

а) мөрәҗәгать итүче булмаган затның әлеге Тәртипнең 1.2 пункты нигезендә мөрәҗәгате;

б) мөрәҗәгать итүченең әлеге Тәртипнең 2.3 пунктында билгеләнгән нормативларны раслау турында гариза тапшыру срокларын үтәмәве;

в) мөрәҗәгать итүченең 2.4 пунктында күрсәтелгән документларны әлеге Тәртипнең 2.5 пунктында билгеләнгән срокта тапшырмавы.

2.11. Нормативларны раслаудан баш тарту әлеге Тәртиптә каралган тәртиптә баш тарту өчен нигез булган сәбәпләр бетерелгәннән соң Дәүләт комитетына кабат мөрәҗәгать итү өчен киртә булып тормый.

2.12. Нормативлар Дәүләт комитеты тарафыннан чираттагы җайга салу чоры башланганчы 1 октябрьгә кадәр әлеге Тәртип нигезендә раслана.

Халык саны биш йөз мең һәм аннан да күбрәк булган җирлекләрдә, шәһәр округларында урнашкан җылылык челтәрләреннән тыш, җылылык энергиясен, җылылык ташучыны җылылык челтәрләре буенча тапшырганда технологик югалтулар нормативларын Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан раслау Тәртибенә 1 нче кушымта

Нормативларны раслау өчен кирәкле документлар исемлеге:

| № т/с | Нормативларны раслау өчен кирәкле документлар исемлеге | Документлар тапшыруга таләпләр | Бирү ысулы |
|---|---|---|---|
| 1<br>2 | Гариза | Язма формадагы оригинал бер нөсхәдә | шәхсән яки почта аша мөрәҗәгать иткәндә |
| | | Бер нөсхәдә сканерланган күчермә | электрон почта яисә ”Электрон Татарстан” электрон документ әйләнеше системасы ярдәмендә җибәрелгәндә |
| 2 | Милек хокукын яисә мөлкәткә ия булуның башка законлы хокукын раслаучы документлар | Бер нөсхәдә күчермә | шәхсән яки почта аша мөрәҗәгать иткәндә |
| | | Бер нөсхәдә сканерланган күчермә | электрон почта яисә «Электрон Татарстан» электрон документлар әйләнеше системасы аша |
| 3 | Шәхесне таныклаучы документ | Төп нөсхәсе | шәхсән мөрәҗәгать иткәндә |
| 4 | Мөрәҗәгать итүченең мәнфәгатьләрен яклауга ышанычнамә | Бер нөсхәдә күчермә | шәхсән яки почта аша мөрәҗәгать иткәндә |
| | | Бер нөсхәдә сканерланган күчермә | электрон почта яисә «Электрон Татарстан» электрон документлар әйләнеше системасы аша |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 5 | Җайга салынулы оешма исеменнән ышанычнамәсез эш итәргә хокукы булган затны билгеләп кую (сайлау) турындагы документ | Бер нөсхәдә күчермә | шәхсән яки почта аша мөрәҗәгать иткәндә |
| | | Бер нөсхәдә сканерланган күчермә | электрон почта яисә «Электрон Татарстан» электрон документлар әйләнеше системасы аша |
| 6 | Рәсәй Федерациясе Энергетика министрлыгының «Җылылык энергиясен, җылылык йөртүчене тапшырганда технологик югалтулар нормативларын билгеләү тәртибен раслау турында» 2008 елның 30 декабрендәге 325 номерлы боерыгы нигезендә, җылылык йөртүчеләрнең норматив технологик чыгымнарын һәм югалтуларын исәпләү, шул исәптән җылылык йөртүченең планлы ремонттан соң җылылык челтәрләренең торбаүткәргечләрен тутыруга, җылылык йөртүчене автомат рәвештә җайга салу һәм саклау чаралары белән технологик агызу чыгымнарын, җылылык йөртүченең планлы эксплуатация сынауларына техник нигезләнгән чыгымнарын һәм җылылык йөртүченең тыгызлыксызлыклары аркасында техник яктан котылгысыз югалтуларын җылылык челтәрләренең арматурасында һәм торбаүткәргечләрендә (һәр җылылык белән тәэмин итү системасы өчен җылылык ташучыларга су, пар һәм конденсат аерым) | Бер нөсхәдә күчермә | шәхсән яки почта аша мөрәҗәгать иткәндә |
| | | Бер нөсхәдә xls, xlsx, ods форматындагы электрон формада | электрон почта яисә «Электрон Татарстан» электрон документ әйләнеше системасы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 7 | Рәсәй Федерациясе Энергетика министрлыгының 2008 елның 30 декабрендәге 325 номерлы «Җылылык энергиясен, җылылык йөртүчене тапшырганда технологик югалтулар нормативларын билгеләү тәртибен раслау турында» боерыгы нигезендә Җылылык энергиясенең норматив технологик чыгымнарын һәм югалтуларын, шул исәптән җылылык йөртүчеләрнең югалтуларын һәм торбаүткәргечләрнең җылылык изоляцияләү конструкцияләре аша (һәр җылылык белән тәэмин итү системасы өчен су һәм пар җылылык челтәрләре буенча аерым) исәпләп чыгару | Бер нөсхәдә күчермә | шәхсән яки почта аша мөрәҗәгать иткәндә |
| | | Бер нөсхәдә xls, xlsx, ods форматындагы электрон формада | электрон почта яисә «Электрон Татарстан» электрон документ әйләнеше системасы |
| 8 | Нормативларны исәпләгәндә кулланыла торган ысулларның тасвирламасы | Бер нөсхәдә күчермә | шәхсән яки почта аша мөрәҗәгать иткәндә |
| | | Сканерланган күчермә яки pdf форматындагы электрон версия (бер данә) | электрон почта яисә «Электрон Татарстан» электрон документ әйләнеше системасы |
| 9 | Технологик югалтулар нормативларын исәпләүнең файдаланыла торган программалары турында белешмәләр (программа исеме, эшләүче исеме, файдаланыла торган версияне эшләү елы, эксперт бәяләмәләре, сертификатлар | Бер нөсхәдә күчермә | шәхсән яки почта аша мөрәҗәгать иткәндә |
| | | Сканерланган күчермә яки pdf форматындагы электрон версия (бер данә) | электрон почта яисә «Электрон Татарстан» электрон документ әйләнеше системасы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | күчермәләре һ. б.) | | |
| 10 | Агымдагы елга һәм агымдагы елга кадәрге ике елга законнарда билгеләнгән тәртиптә расланган нормативлар күрсәткечләре | Бер нөсхәдә күчермә | шәхсән яки почта аша мөрәҗәгать иткәндә |
| | | Сканерланган күчермә яки pdf форматындагы электрон версия (бер данә) | электрон почта яисә «Электрон Татарстан» электрон документ әйләнеше системасы |
| 11 | Коммерция исәбенә алынган күрсәткечләр буенча җылылык энергиясен тапшырганда җылылык чыганакларының, җылылык энергиясенең фактагы югалтулары һәм электр энергиясе чыгымнары күрсәткечләре агымдагы елга кадәрге ике елда | Бер нөсхәдә күчермә | шәхсән яки почта аша мөрәҗәгать иткәндә |
| | | Сканерланган күчермә яки pdf форматындагы электрон версия (бер данә) | электрон почта яисә «Электрон Татарстан» электрон документ әйләнеше системасы |
| 12 | Җылылык энергиясен тапшырганда (булган очракта)технологик югалтулар нормативларының әһәмиятен нигезли торган материалларга экспертиза бәяләмәсе | Бер нөсхәдә күчермә | шәхсән яки почта аша мөрәҗәгать иткәндә |
| | | Сканерланган күчермә яки pdf форматындагы электрон версия (бер данә) | электрон почта яисә «Электрон Татарстан» электрон документ әйләнеше системасы |
| 13 | Аңлатма язуы үз эченә алырга тиеш:<br>- һәр җылылык белән тәэмин итү системасының җылылык энергиясе чыганаклары (җылылык энергиясе чыганакларының Гкал/сәг (кайнар суда) һәм т/сәг (парда)урнаштырылган һәм урнаша торган куәтләре турында белешмәләр<br>- җылылык белән тәэмин итү системаларына характеристика (җайга салына торган, агымдагы елга һәм агымдагы елга кадәрге ике елга), шул исәптән: | Бер нөсхәдә күчермә | шәхсән яки почта аша мөрәҗәгать иткәндә |
| | | Сканерланган күчермә яки pdf форматындагы электрон версия (бер данә) | электрон почта яисә «Электрон Татарстан» электрон документ әйләнеше системасы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | - кайнар су белән тәэмин итүгә һәм жылытуга-вентиляциягә, технологик ихтыяҗларга (Гкал/ч) тоташтырылган исәп-хисап йөкләнешләре;<br>- һәр җылылык белән тәэмин итү системасы буенча җылылык челтәрләренең оешма җитәкчесе тарафыннан расланган актуаль схемасы.<br>- эксплуатацияләү температура графиклары;<br>- җылылык энергиясен җибәрү һәм куллану турында белешмәләр (елга мең Гкал);<br>- җылылык челтәрләренең һәркайсы буенча җылылык челтәрләре торбаүткәргечләренең озынлыгы, күләме, торбаүткәргечләрнең җылылык изоляциясе конструкцияләренең тибы, җылылык челтәрләрен файдалануга тапшыру еллары турында белешмәләр<br>- җылылык ташучының, грунтның, тышкы һаваның, җылылык челтәрләрен тукландыру өчен файдаланыла торган башлангыч суның җылылык һәм җылылык белән тәэмин итү чорындагы уртача еллык һәм уртача температуралары<br>- һәр җылылык челтәренең җылыту һәм җылыту чорларында эшләве дәвамлылыгы, җылылык челтәрләрен планлы ремонтлау һәм эксплуатацион сынаулар үткәрү өчен сүндерүләр дәвамлылыгы<br>- җылылык энергиясен тапшырганда кулланыла торган кулланыла торган | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | куәтнең саны, мөрәҗәгать итүче тарафыннан файдаланыла торган насос һәм башка электрлаштырылган җайланманың файдалы гамәл коэффициентлары турында белешмәләр, күрсәтелгән җайланманың характеристикалары, насос төркемнәре буенча суыртыла торган җылылык ташучының һәм барлыкка килә торган басымнарның җылыту һәм җылыту чорына уртача чыгымнары турында белешмәләр җылылык челтәренең эш режимы, әлеге җайланманы җайга салына торган чорда куллану дәвамлылыгы<br>- җайга салына торган чор башланганчы биш елдан да иртәрәк төзелмәгән 50 Гкал/сәг һәм аннан да күбрәк исәпләнгән җылылык йөкләнеше булган җылылык челтәрләренең норматив энергетик характеристикалары, шулай ук норматив энергетик характеристикаларны эшләгәндә кабул ителгән башлангыч мәгълүматларны җайга салына торган чорга фаразлана торган мәгълүматлар белән чагыштыру нәтиҗәләре<br>- җайга салына торган чор башланганчы кимендә биш ел алдан үткәрелгән җылылык челтәрләрен энергетик тикшерү хисаплары һәм нәтиҗәләре<br>- оешманың инвестиция программасы нигезендә җылылык челтәре аша җылылык энергиясен тапшырганда технологик югалтуларны киметүгә | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | юнәлдерелгән энергияне сак тоту чаралары исемлеге | | |
| 14 | Җылылык белән тәэмин итүче оешма объектларының техник характеристикалары белән тутырылган шаблон https://kt.tatarstan.ru/shabloni-formi.htm | Бер нөсхәдә күчермә | шәхсән яки почта аша мөрәҗәгать иткәндә |
| | | Бер нөсхәдә, xlsx, ods форматындагы электрон формада | электрон почта яисә «Электрон Татарстан» электрон документ әйләнеше системасы |
| 15 | «РаТеН-325» программа тәэминатында җылылык белән тәэмин итүче оешманың җылылык челтәрләренең техник параметрлары белән тутырылган формасы: https://kt.tatarstan.ru/shabloni-formi.htm | Электрон рәвештә | шәхсән яки почта аша мөрәҗәгать иткәндә, электрон почта яисә «Электрон Татарстан» электрон документ әйләнеше системасы |

Халык саны биш йөз мең һәм аннан да күбрәк булган җирлекләрдә, шәһәр округларында урнашкан җылылык челтәрләреннән тыш, җылылык энергиясен, җылылык ташучыны җылылык челтәрләре буенча тапшырганда технологик югалтулар нормативларын Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан раслау Тәртибенә 2 нче кушымта

Оешманың фирма бланкында (булган очракта)

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт
комитеты рәисенә
_____________________________
(инициаллар, фамилия)

ГАРИЗА

Мөрәҗәгать итүче:________________________________________________________
Ф.И.О. (атасының исеме - булган очракта) шәхси эшмәкәр яисә юридик зат исеме (җайга салынулы оешма уставы нигезендә), җитәкченең фамилиясе, исеме һәм атасының исеме

Оешма реквизитлары:_______________________________________________________
ИНН, ОГРН / ОГРИП оешмасы, аны бирү датасы

_____________________________________________________________________________
юридик затны (шәхси эшмәкәр теркәү турында карар кабул иткән орган исеме (юридик зат буларак дәүләт теркәве турында таныклык яисә физик затны шәхси эшмәкәр буларак дәүләт теркәве турында таныклык нигезендә)

Юридик адрес/шәхси эшмәкәр сыйфатында физик затның яшәү урыны:___________________________________________________________________

_____________________________________________________________________________

Почта адресы:_____________________________________________________________

Идарә органнарының факттагы урнашу урыны адресы: _____________________________________________________________________________

Элемтә телефоннары ______________________________________________________

“Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайт (булган очракта)____________________________________________________________

Юридик затның яисә шәхси эшмәкәрнең электрон почта адресы___________________________________________________________________

Норматив төре:__________________________________________________________

Җайга салу чоры: _______________________________________________________

Кушымта: ____________________________________________________________

(беркетелгән документларның кыскача тасвирламасы)

Оешма җитәкчесе (имзаның расшифровкасы)

Дата

Оешма мөһере
*(булган очракта)*

Башкаручы - Ф.И.О. (атасының исеме - булган очракта)
Элемтә телефоны: